**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.09.2023 Казан № 357

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре катнашкан һәм һәркемгә ачык мәгълүмат, шулай ук аларны аңларга мөмкинлек бирүче белешмәләр урнаштырган «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә сайт һәм (яки) сайт битләре адреслары турында мәгълүматны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 202 маддәсенә, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 172 маддәсенә ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1. Кушымта буларак бирелгән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре катнашкан һәм һәркемгә ачык мәгълүмат һәм аларны аңларга мөмкинлек бирүче белешмәләр урнаштырган «Интернет» мәгълүмати- телекоммуникацион челтәрендә сайт һәм (яки) сайт битләре адреслары турында мәгълүматны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен расларга.

2.Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Министр Р.Н.Садыйков

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
Министрлыгы боерыгы
белән расланды
19.09.2023 № 357

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре катнашкан һәм һәркемгә ачык мәгълүмат һәм аларны аңларга мөмкинлек бирүче белешмәләр урнаштырган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә сайт һәм (яки) сайт битләре адреслары турында мәгълүматны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип билгели:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга (алга таба – граждан), һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә(алга таба – граждан хезмәткәре, министрлык) һәркемгә ачык мәгълүмат, шулай ук аларны аңларга мөмкинлек бирүче белешмәләр урнаштырган «Интернет» мәгълүмати- телекоммуникацион челтәрендә сайт һәм (яки) сайт битләре адреслары турында мәгълүмат бирү кагыйдәләре (алга таба сайтлар турында мәгълүмат, Интернет челтәре);

Сайтлар турындагы мәгълүматларны эшкәртү һәм кабул итү тәртибе;

Сайтлар турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе.

2. «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль Законның 7 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә ачык мәгълүмат дип һәркемгә ачык мәгълүматлар һәм аңа керү чикләнмәгән башка мәгълүмат аңлатыла. Шул ук вакытта мәгълүматка керүдә чикләүләр булмау чикләнмәгән төркем кешеләрнең урнаштырылган мәгълүматны гражданлык хезмәткәре һәм гражданның ризалыгыннан башка тоткарлыксыз алу һәм үз ихтыяры буенча куллану мөмкинлеген күздә тота.

3.Гражданлык хезмәткәренең яки гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүмат буларак, түбәндәге мәгълүматларның җыелмасы яки аларның берсе булырга мөмкин: фамилиясе, исеме, фотосурәте, эш урыны.

II. Сайтлар турындагы мәгълүматларны эшкәртү һәм кабул итү тәртибе

4.Сайтлар турында белешмәләр билгели:

Граждан - Татарстан Республикасы дәүләт гражданлак хезмәтенә (алга таба –

гражданлык хезмәте) аңа кадәрге өч календарь ел өчен кергәндә.

граждан хезмәткәре ел саен киләсе елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча

отчет елы, алдагы календарь елы өчен.

5. Гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан сайтлар турында мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән формада тәкъдим ителә(алга таба-форма).

6. Һәркемгә ачык мәгълүмат граждан хезмәткәре вазыйфаларын башкару кысаларында урнаштырылган булса, ул Формада чагылдырылырга тиеш түгел.

7. Форма граждан хезмәткәре тарафыннан тутырыла һәм Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контуры аша бастырыла. Гражданлык хезмәткәрләре яки гражданнар тарафыннан тутырылган Форма Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры ( Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры вазыйфаларын башкаручы зат) боерыгы белән( алга таба – министр)сайтлар турындагы мәгълүматларны эшкәртү өчен җаваплы итеп билгеләнгән дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлеге хезмәткәренә тапшырыла(алга таба-җаваплы зат).

8. Җаваплы зат Форманың дөрес һәм тулы тутырылган булуын тикшерә, «Интернет» челтәре ярдәмендә күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя.

9. Формада тутырылмаган полялар калган очракта, ул кабул ителми.

10.Әгәр граждан тәкъдим иткән формада дөрес булмаган мәгълүматлар табылса, дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлеге шунда ук гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләнүне кире кагу турында хәбәр итә.

11. Җаваплы зат «Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Мәгълүмат системасында граждан хезмәткәрләренең шәхси карточкаларындагы сайтлар турында мәгълүматларның дөрес тутырылышын тикшерә.

12. Гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тәкъдим иткән Формалар гражданлык хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлегендә биш ел дәвамында саклана, шуннан соң Министрлыкта шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләрендә күрсәтелгәнчә юк ителә.

## III. Сайтлар турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13 Гражданнар һәм гражданлык хезмәткәрләре тәкъдим иткән сайтлар турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү министр (министр вазыйфаларын үтәүче) (алга таба – министр) боерыгы нигезендә эшләнә.

14. Язма рәвештә тәкъдим ителгән җитәрлек мәгълүмат нигез булып тора:

Хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнары һәм закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган башка гомумроссия, төбәк-ара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләре;

Татарстан Республикасы иҗтимагый палатасы;

Россия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

15. Җаваплы зат граждан хезмәткәренә тикшерү турында боерык чыкканнан соң, ике эш көне эчендә тикшерү үткәреләчәге турында язма формада хәбәр итә.

16. Граждан хезмәткәре тәкъдим иткән сайтлар турында мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү җаваплы кеше тарафыннан «Интернет» челтәрендә урнаштырылган гомуми кулланышта булган мәгълүматны эзләү һәм күрсәтелгән мәгълүматның электрон күчермәләрнең (скриншотларын) булдыру аша башкарыла.

17. Граждан хезмәткәре тикшерү нәтиҗәләре буенча язма аңлатмалар бирергә һәм өстәмә материаллар тәкъдим итәргә хокуклы.

18 Әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалына беркетелә.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган мәгълүмат тикшерү үткәрү турында боерык чыкканнан соң, 10 көннән дә соңга калмыйча, министрга тапшырыла. .

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көн эчендә министр карар кабул итә:

Гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләр булмавы турында;

Гражданлык хезмәткәренә юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

Хокук бозу, җинаять, экстремистик эшчәнлеккә кагылышлы билгеләр булганда тикшерү материалларын дәүләт органнарына, аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрү турында.

21.Министр кабул иткән карар турында җаваплы зат тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә ике эш көне эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

22. Сайтлар турында мәгълүмат министрның язма ризалыгы белән бер үк вакытта тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә, хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең даими эшләүче житәкче органнарына һәм, шәхси мәгълүматлар һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын саклап, һәм сәяси булмаган партияләр, башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләре, Татарстан Республикасы иҗтимагый палатасы, тикшерү өчен нигез булып торган мәгълүмат биргән Россия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итү белән бирелергә мөмкин.

23. Тикшерү материаллары дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлегендә өч ел дәвамында саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматларның тәкъдим ителмәве өчен җаваплылык

24. Сайтлар турындагы мәгълүматларны бирмәгән очракта гражданин гражданлык хезмәтенә алынырга тиеш түгел, ә гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтен дәвам итә алмый.

25. Гражданлык хезмәткәренең сайтлар турында мәгълүмат бирмәве хокук бозу булып санала, һәм ул граждан хезмәтеннән азат ителә.